ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.06.2021 ел Баулы шәһәре №99

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 29 мартындагы 47 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә - хезмәткәрләргә акчалата түләүләр бирү тәртибенә өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 14 декабрендәге «Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче физкультура спорт оешмаларының хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 1134 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 29 мартындагы 47 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә - хезмәткәрләргә акчалата түләүләр бирү тәртибенә түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

3 пунктның икенче абзацында «, физкультура-спорт оешмалары инструкторы-методисты, физкультура-спорт оешмалары өлкән инструктор-методисты» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.И. Хөснуллина